# ВАКЫТЛЫ ҺӘМ УРЫНЛЫ ЯЗЫЛГАН ХЕЗМӘТ

Халык язучысы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗатын, аның дөньяга карашын, шәхес буларак үзенчәлекләрен өйрәнү — әдәбият галимнәрен генә түгел, һәркемне кызыксындыра һәм мавыктыра торган шөгыль. Әлеге хезмәтнең авторы да, эшкә керешкәндә, М. Мәһдиев иҗатының бу ягын, тармагын белгәнлеген күрсәтүне максат итеп куймаган. Үзе әйтүенчә, язучының публицистик мәкаләләрен укый башлагач мавыгып киткән һәм әле тулысынча үзләштереп бетерелмәгән иҗат төре, стиле барлыгын күргән.

М. Мәһдиевнең публицистик рухтагы мәкаләләре турында әйтелгән фикерләр, аларга бирелгән бәяләр аз түгел. Фәридә Гайфуллина алар белән яхшы таныш икәнлеген гадел рәвештә күрсәтеп барган. Әлеге хезмәтнең уңышлы ягы, кыйммәте — язучының күрсәтелгән еллар арасында төрле газета-журналларда басылып чыккан мәкаләләрен бергә туплап, аларны бер системага, эзлекле тәртипкә салып анализлавында.

Иң беренче фикер дә шул тәртип, ягъни хезмәттә анализ юнәлешләре турында. Ф. Гайфуллина тематик бүленеш принцибын сайламаган, мәкаләләр арасындагы фикер, хис һәм мөнәсәбәтләр бәйләнешен, иҗади уртаклыкларны эзләгән, ачыклаган. Хезмәтнең структурасы да шул принципка корылган. Бүлекләрнең күләме дә, табигый буларак, төрле, һәм бу аклана да.

Фәридә Гайфуллина татар әдәбиятының чын мәгънәсендә халык язучысы булган һәм әдәбият үсешенең төп традицион агымы уртасында торган, шул ук вакытта бер язучыга да охшамаган стиле — сурәтләү объекты, геройлары һәм үзенең аларга мөнәсәбәте, аеруча кабатланмас сурәтле теле, сөйләме белән аерылып торган Мөхәммәт Мәһдиевне нинди итеп күрә, бәяли соң?

Беренчедән, татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак (күп еллар Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә укыта), ул әдипнең әсәрләрен, иҗатын яхшы белә, алар турында укучыларына җиткерә. Әдәбият галиме бу-

ларак та (филология фәннәре кандидаты), әсәрләренең сәнгатьчә кыйммәтен һәм мәкаләләрдәге төп мәсьәлә-проблемаларны фәнни төгәллек, сизгерлек белән бәяли ала. Өстәвенә М. Мәһдиевнең якташы, укучысы, аның белән очрашып яшәгән, фикердәш кеше буларак та, язучының тормышка карашы аңа якын, кадерле икәнлеге хезмәттә ачык сизелә.

Икенчедән, бу хезмәттә М. Мәһдиевнең галим һәм язучы буларак талант сыйфатлары, иҗади фикерләү берлеге ассызыклана. Язучыны якыннан белгән, иҗатын яраткан кешеләр, укучылар да бу фикер белән килешми калмас: Мөхәммәт Мәһдиевнең бик күп белүе, талантлы булуы аның публицистик мәкаләләренә шундый ышандыру куәте биргән дә. Әле дә яхшы хәтерлим: катлаулы проблемалар алдында калганда, галимнәр дә, гади кешеләр дә: «Бу турыда Мәһдиев ни әйтә, ни уйлый?» — дип кызыксына килде. Аның мәкаләләрен эзләп таба, әдәби әсәрләрен кабат алып укый иде.

Өченчедән, Фәридә Гайфуллина язучының публицистик мәкаләләре иҗатының һәм яшәү-фикерләвенең аерылгысыз бер җебе, тармагы икәнлеген бик анык исбатлап бара. Бу фикер М. Мәһдиевнең тарихчы галим буларак эшчәнлеген анализлаган бүлекләрдә аеруча ачык чагыла. Язучының тарихны архивлардан эзләп, документлар, кулъязмаларда яңа исемнәр, тарихи фактлар табуы үзмаксат түгел икәнлеге дә хаклы рәвештә искәртеп барыла.

Язучы үзенең язмышы, гомер юлы белән дә тарихның җанлы бер шаһиты икәнлеген аңлап, тоеп яшәде. Бу хезмәттә дөньяга караш, тарихи хәрәкәтнең перспективасын күрә белү сәләтенә аеруча игътибар бирелә. М. Мәһдиев мәкаләләрендә кабатланып, аларны үзара ялгап торган фикер җебе — тарихтан бүгенгә килеп җиткән, нәтиҗә булып формалашкан сәбәпләрне, хакыйкатьне эзләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше. Нәкъ шушы мәгънәдә язучы, тарихчы, галим бер шәхес булып гәүдәләнә дә. Хәер, галим дигәндә, М. Мәһдиев тарихчы һәм әдәбиятчы синтезы да иде. Үз иҗат тәҗрибәсе, татар әдәбиятының тарихын, язучылар биографиясен, әсәрләр язмышын реаль белүе аны аерылгысыз рәвештә әдәбиятчы итеп формалаштырды. Хезмәттә бу хакыйкать тә раслана.

Гомуми иҗат процессын бербөтен итеп күзалласак, М. Мәһдиевнең публицистикасы аның матур әдәби әсәрләреннән, төп иҗатыннан аерылгысыз кебек. Хәер, төп эшчәнлеге язучылыкмы, укытучылык идеме икәнлеген аерып та булмый, чөнки укыту эшендә дә (мәктәптәме, вуздамы) ул чын иҗатчы иде.

Шулай да публицистикасы турында аерып алып сөйләшү, махсус хезмәт язу гаять урынлы, зарури гамәл: беренчедән, әдәби әсәр стилендә «рөхсәт ителмәгән» кискенлек, үткенлек һәм фикерне өздереп әйтү – публицистиканың төп сыйфаты, бурычы. М. Мәһдиев һәр мәкаләсендә йә фактик, йә тарихи ачыш ясый, яисә конкрет проблема куя һәм үз фикерен шактый кискен итеп әйтә. Бу – шәхес буларак аның хокукы. Хәлбуки кайбер очракта (мәсәлән, интеллигенция турында) бәхәсләшәсе дә килә, үзе исән булса, бәхәсләшер, аңлашыр да идек, әлбәттә.

Икенчедән, М. Мәһдиев әдәби әсәрләрендә генә түгел, шәхес буларак, зур мәгънәдә милләтче буларак, Габдулла Тукай, Фатих Әмирханнар традициясен дәвам итте. Аның публицистик мәкаләләре шуны раслап тора.

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә:

– М. Мәһдиев гап-гади Гөберчәк авылын һәр татар укучысының җанына якын, таныш туган ягына әйләндергән шәхес булды;

– үзе укыткан укучы-шәкертләренең сөекле остазы иде, аның күңел җылысы мәктәп укытучыларына, укучыларына күчә бара;

– үз чорында зур галимнәр, каләмдәшләре тарафыннан ихтирам казанды, әдәбият мәйданында гаделсез киртәләрне җимереп танылды.

М. Мәһдиев иҗатын фәнни юнәлештә анализлап, публицистикасының иҗтимагый, тарихи һәм сәнгатьчә әһәмиятен бәяләп язылган хезмәт аеруча вакытлы, урынлы дип кабул ителә.

***Флёра Ганиева,***
*филология фәннәре докторы*

# КАБАТЛАНМАС ШӘХЕС

Мөхәммәт Мәһдиев – үзенчәлекле, затлы шәхес. Ул – халкыбызның яраткан язучысы, күренекле галим, кыю публицист, күпләрнең кадерле укытучысы…

Юкка гына М. Мәһдиев лекцияләрен тыңлаган укучылар арасыннан язучылар һәм шагыйрьләр чыкмагандыр. Аның һәр лекциясе көтеп алына, йотлыгып тыңлана иде. Ул лекцияләр бай эчтәлекле һәм кызыклы булды. Безне дөньяны таныргa, уйларга, фикерләргә өйрәтте Мөхәммәт ага. Шул юл белән әдәбиятка мәхәббәт уятты, иҗатка рухландырды.

Язучы буларак та беркемне дә кабатламаган, үз йөзе булган, үз фикерен туры итеп әйтә белгән әсәрләр иҗат итте: татар әдәби теленең үрнәге итеп алырлык повесть-романнар калдырып китте. Аларда халыкның җор, үткен телен, тапкыр акылын, холкын, тарихын күрсәтте.

М. Мәһдиев – прозага китаптан түгел, ә тормышның үзеннән, олы юл үтеп, зур тәҗрибә туплап килгән язучы. Шуңа да аның «Без – кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар», «Каз канатлары», «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Ут чәчәге», «Мәңгелек яз», «Ачы тәҗрибә», «Бәхилләшү» кебек әсәрләре әдәбиятыбыз түрендә лаеклы урын тапты.

М. Мәһдиев әсәрләренең тематикасы искиткеч киң. Шулар арасында аерылып торганы – тормышның үзе, кеше язмышлары. Ә тормышы аның авыл белән, авылдашлары белән тыгыз бәйләнгән. Халкыбызның, милләтебезнең терәге булган татар авылының тарихын, язмышын аңардан да яхшы белгән, шулкадәр тирән тасвирлаган язучы юктыр.

Бу серле, талантлы язучының повесть-романнарында укучыны беренче юлларыннан ук үзенә бөтереп алып кереп китә торган сюжет та, тирән һәм катлаулы конфликт та юк кебек. Чынлыкта исә аның әсәрләре күптармаклы,

күпсызыклы сюжетка корылган. Әдипнең һәр характеры үзе бер тәмамланган новелла булып тора. Бу әсәрләр ниндидер тылсым белән сине сихерләп ала да, ахырына кадәр җибәрмичә, шундагы вакыйгалар эчендә кайната, шундагы геройлар белән яшәтә. Аның әсәрләрендә, тирән фәлсәфә белән бергә, халкын яратуы, аны сөеп, ачуланып яки аннан оялып милләтебезнең асыл сыйфатларын кайтарырга теләве чагыла. Язучыны олы дөнья проблемалары борчый, Җир шары сулышы аның йөрәге аша уза.

М. Мәһдиев, филология фәннәре кандидаты, галим буларак, «Әдәбият һәм чынбарлык» (1987), «Реализмга таба» (1989), «Социальные корни таланта» (1990) хезмәтләрен бастыра. Ул татар иҗтимагый фикер үсешен, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть тарихын, халык авыз иҗатын фәнни өйрәнү мәсьәләләре белән яшьтән үк кызыксына. Галимнең XIX йөз ахыры — XX йөз башы татар мәгърифәтче педагоглары, аннан соңгы күп кенә әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре турында архив материалларына нигезләнеп язылган мәкаләләре, иҗат портретлары, фольклористика һәм әдәбият фәненең аерым проблемаларын тикшергән бик күп гыйльми-тәнкыйди хезмәтләре бар. Болар — киләчәк буынга үрнәк булырлык ядкярләр.

Тыелган, онытылган әдәби мирасны халыкка кире кайтаруда да М. Мәһдиев әйтеп бетергесез зур эшчәнлек күрсәтә. Аның әдәбият тарихына кагылышлы мәкаләләр саны гына да биш йөздән артык. «Мөхәммәт Мәһдиевнең хәтере ныклыгына, иманының көрлегенә шаккатарлык! Шушы еллар эчендә ул күпме югалган исемнәрне, без белмәгән документаль фактларны, әдәбиятта онытылып торган вакыйгаларны көнгә чыгарды»[1], — дип язды халык язучысы Аяз Гыйләҗев.

М. Мәһдиев үзен тәҗрибәле, үткен телле публицист буларак та танытты. Киң катлау укучы аңына йогынты ясау максатын күздә тоткан иҗтимагый-сәяси эчтәлекле бу әдәби төрне бик тиз үз итте, бүгенге көннең иң актуаль проблемаларын яктырткан язмалары белән халыкны сөендереп торды.

Язучының публицистик язмаларын бер сулышта укып чыгасың һәм башкалар белән дә уртаклашырга ашыгасың. Чөнки ул чынбарлыкны ничек бар, шулай сурәтли, дөнья-

---

[1] *Гыйләҗев А.* Сайланып чыккан сүзләр… // М. Мәһдиев. Кеше китә — җыры кала. — Казан : «Татар китабы» нәшр., 1996. — 25 б.